**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР СУКСУЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423736, Татар Суксуы авылы,
Гагарин урамы
1 б нче йорт. Тел. 3-44-60
e-mail: tsuk-akt@yandex.ru

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ТАТАРСКО-СУКСИНСКИЙ**
**СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423736, село Татарские Суксы,
ул. Гагарина,
дом 1 б. Тел. 3-44-60
e-mail: tsuk-akt@yandex.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«10» май 2021 ел №7

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге башкарма комитетының 2013 елның 11 февралендәге 3 номерлы «Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 бүлегенең 7 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының административ регламентлары проектларын эшләү һәм килештерү дәүләт мәгълүмат системасында һәм (яки) муниципаль мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хезмәтләре реестрын, муниципаль хезмәтләр реестрын электрон рәвештә алып баруны тәэмин итә»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Татар Суксуы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татар Суксуы авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Г.Г. Хамматуллина